СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 1-17 от «29» мая 2017 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә торак пункт төзелү мәсьәләләре белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына инициатива белән чыгу турында

“Географик объект атамалары турында” 18.12.1997 ел, 152 нче номерлы Федераль Законның 9 статьясы, “Татарстан Республикасының административ –териториаль төзелеше турында” 07.12.2005 ел, 116 нчы номерлы ” Татарстан Республикасы Законының 13, 17 статьялары, 26.05.2017 ел 1-23 нче номерлы Урманчы авыл җирлегенең Советы Мамадыш муниципаль район Советына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә торак пункт төзелү мәсьәләләре белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына инициатива белән чыгу турында тәкъдиме нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына каралуга кертергә:

   1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориясендә торак пункты төзергә һәм аңа исем бирергә:

   –Урманчы авыл җирлеге территориясендә– Тарасово поселогы.

2. Мамадыш муниципаль районы Советының 24.01.2012 нче елда кабул ителгән № 6-10 санлы карарын гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

3. Әлеге карарны һәм аңа кушылган яңа торак пункты төзелү турында материалларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны район башлыгы урынбасары, муниципаль район Советы рәисе урынбасары Р.Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе А.П.Иванов